ЯШЕЛ БИШЕК

ТР ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘНГӘН МАХСУС КУШЫМТА

Хөрмәтле экологлар!

Сезне һөнәри бәйрәмегез – Экологлар һәм бөтендөнья әйләнә-тирә мохитне саклау көне белән җылы һәм эчкерсез котлыйм!

Бөтен Җир шарын һәм анда яшәүчеләр тормышын саклаучы бер генә һөнәр бар дөньяда. Эколог һөнәре ул.

Экологик имин лекне тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне савыктыру, Татарстанның махсус сакланышлы табигый территорияләре эшчәнлегенә күз-колак булып тору бик зур җаваплылык, һөнәри осталык таләп итә. Һичшиксез, бу мөһим эшкә дәүләт оешмалары, предприятиеләр, иҗтимагый оешмалар экологлары, гомумән, табигатькә битараф булмаган гап-гади кешеләр дә саллы өлеш кертә.

Республикабызда әйләнә-тирә мохитне саклау, төбәкнең экологик торышын яхшырту өлкәсендә әйбәт кенә тәҗрибә тупланды. Автомобиль техникасына карата таләпләр елдан-ел кискенләшә, икътисадның төрле тармакларындагы җитештерүдә экологик нормалар катгыйрак контрольдә тотыла.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы Татарстанда яшәүче барча кешене табигатьне яратырга, экологик культураны үстерергә һәм Татарстанда урнашкан махсус сакланылышлы территорияләрне күз карасыдай саклап тоту эшендә актив катнашырга өнди. Безнең гомуми максат – һавабызның сафлыгын, елга-күлләребезнең чисталыгын, җирләребезнең үңдырышлылыгын, урманнарыбызның байлыгын, шулай ук республикабызны бизәп торучы үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының төрлелеген саклау. Уртак тырышлыкларыбыз белән генә илебезнең табигый байлыкларын саклап кала алуыбызга иманым камил. Табигатькә һәм, гомумән, бөтен тереклек дөньясына ихтирамлы мөнәсәбәт, киләчәккә ышаныч һәм осталарга эшли белү республикабызның табигый мирасын саклап калу гына түгел, бәлки аны баету мөмкинлеге дә бирәчәк.

Татарстан Республикасы
экология һәм табигый байлыклар министры
Ә.К.САДРЕТДИНОВ

Гөлт иттекме?

ЧИСТАРАБЫЗ

Республикада чисталык икеайлыгы тәмамланды. 1 апрельдән алып 1 июньгә кадәр белгечләр тарафыннан барлыгы биш меңнән артык объект тикшерелде, аларның 4685ендә хокук бозу очраклары ачыкланды.

Республиканың экология һәм табигый байлыклар министры Әгъләм Садретдинов әйтүенчә, ел саен үткәрелә торган мондый чараның әһәмияте зур. Алдагы еллар тәҗрибәсеннән чыгып шундый нәтиҗә ясарга була, диде ул журналистлар белән очрашуда. Быел табигатькә зыян китерүчеләргә карата 6 миллион сумнан артык штраф салынган, прокуратурага тикшерү өчен 81 материал юлланган булуы моны кабат раслады.

Ләкин чистарту-агарту эшләрен алып барып, зур суммада штраф түләтүгә дә карамастан, тирә-якның чисталыгы һич тә көн үзәгеннән төшми.

– Әлегә ул ямьсез күренешләрнең нәтиҗәләре белән көрәшәбез. Чынлыкта исә аның сәбәпләрен үк юк итәргә кирәк, – ди бу хакта экологлар.

– Әгәр кеше өендәге чүпне вакытында түгеп, кушшын гел чистартып торган кебек, урамда, табигать кочагында да үзен шулай тотса, мондый икеайлыкларның кирәге дә калмас иде, – ди Әгъләм Кыямович. Шулай да министр быелгы эшләрдән тулаем канәгать калуын белдерде. – Бер генә муниципаль оешма җитәкчесенең дә бүген кәефен кырасы килми. Бик күләмле һәм зур эш башкарылды. Биектау, Актаныш, Арча, Чүпрәле, Балтач, Теләче районнары, мисал өчен, яшелләндерү, тирә-якны төзекләндерүдә өлгерлек күрсәтте. Иминлек корылмаларын тиешле дәрәҗәгә китерү буенча Чаллы, Лениногорск шәһәрләрен, Биектау белән Мөслим районнарын телгә алырга була. Казанда, Чаллыда, Түбән Камада, Бөгелмәдә балалар өчен төзелгән уен мәйданнары күркәмлекләре белән күз явын алып тора.

Икеайлык барышында башкала буенча барлыгы тугыз йөздән артык тикшерү рейдлары уздырылган. Аның барышында меңнән артык хокук бозу очрагы ачыкланып, барлыгы ике миллион сумга якын штраф салынган. Законсыз рәвештә оештырылган чүплекләрнең күплеге экологларны да сүзсез калырга мәҗбүр итә. Казан буенча гына да ел дәвамында җиде йөзгә якын (!) шундый законсыз чүплек барлыкка килгән. Министрның, вертолетка утырып, Лаеш, Питрәч, Казанның Совет районы җирләрен һавадан күзәтүе дә нәтиҗәсез калмаган. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча бүген һәр районда эш бара. "Законсыз оештырылган чүплекләрнең 90 проценты юк ителде", – ди министр бу уңайдан.

Республикадагы икеайлык уңаеннан бер миллионга якын кеше табигатькә файдалы эш башкарган. Алар барлыгы өч йөз меңгә якын агач һәм куаклык утырткан. Кулланылышта булган чүп контейнерлары төзекләндерелеп, алар янына яңалары куелган. Муниципаль районнар җирләреннән җыеп алынган дүрт йөз мең кубометрдан артык каты көнкүреш калдыгы полигоннарга озатылган.

Полигон дигәннән, аларның да кайберләрендә таләпләрнең бозылуы ачыкланган. Шундый унике "чүп базары" бүген "хаталар өстендә эш" эшли. Белгечләр полигоннардагы мондый хәлне чиксез күләмдә системасыз түгелгән чүп белән аңлата. Кинәт кенә өем-өем китереп ташланган чүпне полигоннар эшкәртеп бетерә алмый, ди алар.

Тикшерү барышында машинага төялгән чүпләрнең полигонга җитмичә бушатылу очраклары да теркәлгән.

– Юл кырыйларында, урман яннарында андый урыннарны күп күрдек, – ди министр. – Эшмәкәрләрнең акча түлиселәре килми. Ә түләүсез эш бүген беркайда да юк. Әйтик, шул ук полигонда эшләүчегә хезмәт хакы түләргә, транспорт чараларын ягулык, запас частьләр белән тәэмин итәргә кирәк. Тиен кызгану аркасында табигатькә меңәр сумлык зыян салына. Юктан гына күпме өстәмә эш барлыкка килә.

Экологлар фикеренчә, шушы рәвешле чүп арасында көн күрүебезгә без – кешеләр үзебез гаепле. Бу безнең тәрбиясезлектән, культурасыз булуыбыздан килә. Рейдлар вакытында ачыкланган житешсезлекләргә генә күз салыйк. Аларның 40 проценты автотранспорт чараларын яшеллек зоналарында калдыруга бәйле. 20 проценты исә өй яны контейнерларының вакытында бушатылмавына бәйле. Икеайлык вакытында "кайнар элемтә" аша килгән хәбәрләрдән республикада барган капиталь ремонтның чүп арттыруда өлеше зур булуын раслаган. Иске төзелеш калдыкларын алып китеп, тиешле урынга бушатмаганга күрә андый йортларның әйләнә-тирәсе шулай ук чүп таулары белән чуарлана.

Чулпан ХӘЙРУЛЛИНА

Җиңүегез белән!

В.Д.Шашин исемендәге "Татнефть" ААҖне "Экологик сәясәт" номинациясендә "Экомир" илкүләм экологик премия лауреаты исеменә лаек булуы һәм "2000-2015 елларга "Татнефть" ААҖнең экологик программасы" өчен I дәрәҗә махсус диплом белән бүләкләнүе, Түбән Кама "Нефтехим" ААҖне "2007-2015 елларга Түбән Кама "Нефтехим" ААҖнең экологик программасы. 2004-2008 елларга әйләнә-тирә мохитне идарә итү программасы" өчен I дәрәҗә лауреат исеме бирелде.

Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры Әгъләм Садретдинов нефтьчеләр һәм нефтехимикларны шушы уңайдан тәбрик итә.

Кама буе чәчәкләре

Чаллы шәһәренең экология музеенда Җир көнен билгеләп үттеләр. Ул "Кама буе чәчәкләре" дип исемләнгән күргәзмә оештырудан гыйбарәт булды. Чараның әһәмиятен сөйләп тә, аңлатып та бетерергә мөмкин түгел. Биредә Җир- анадa булган яшел даруханә байлыклары тәкъдир ителде, кешеләргә табигатьтәге шифаның никадәр бай булуын аңларга мөмкинлек тудырылды. Тәкъдим ителгән яшеллекләр арасында дөньяда билгеле булган чәчкә семьялыкларның һәрберсеннән диярлек "вәкил" бар иде. Республиканың Кызыл китабына кертелгән май ландышы, гади артыш агачы, песи үләне, сары җитен кебек бик сирәк очрый торган үләннәрне дә биредә күрергә мөмкин булды.

Хәзерге вакытта күргәзмәдә урын алган үләннәрнең күбесенә юкка чыгу куркынычы яный. Белгечләр моны авыл хуҗалыгы эшләре белән дә бәйләп аңлата. Мисал өчен, җирләрне сукалаганда, терлекләрне далага чыгарганда, яисә төзелеш эшләре алып барганда табигать даруханәсенә шактый зыян салына.

Үләннәрдән тыш күргәзмәдә тропик якларда гына үсүче чинар, карамбола, кипарис кебек уникаль үсемлекләрнең орлыкларын, җимешләрен дә күрергә насыйп булды. Әстерхан, кокос чикләвекләренә дә урын табылган булып чыкты.

– Мондый кызыклы экспозицияләрне булдыру өчен музей хезмәткәрләренә күп кенә әдәбият укырга, белешмә-китапларны өйрәнергә туры килде, – ди Чаллының Картиналар галереясы директоры Ф. Гайнетдинова.

Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе башлыгы Айрат Насыйбуллин әйтүенчә, мондый чараларның экологик белем бирүдә һәм халыкның хәбәрдарлыгын арттырудагы әһәмияте гаять зур.

Алинә ХӘБИБУЛЛИНА

Ык буенда ... ыңгыраш

КОМИССИЯ ЭШТӘ

Республиканың экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиологик иминлек буенча оештырылган ведомствоара комиссиясе айдан-айга регионнарны тикшереп кенә тора. Күптән түгел комиссия вәкилләре Азнакай, Баулы, Мөслим һәм Ютазы районнарын берләштерүче Ык буе регионы торышы белән кызыксынып кайтты.

Җир астындагы байлыкның җир өстенә зыяны

Ык буе регионында бүген 146 меңнән артык кеше яши. Биредәгеләр туган якларының нефтькә бай булуы белән мактана ала. Аларның төп хуҗалык эшчәнлеге дә иң беренче чиратта нефть чыгаруга бәйле. Шуңа бәйле рәвештә, биредә күпләгән санда нефть сәнәгате предприятиеләре урын алган. Аларның эшчәнлеге исә төбәк табигатенә, экологиясенә шактый зыян сала. Соңгы елларда белгечләр регионның экологик торышын уртачадан да түбән дип бәяләргә мәҗбүр. Әйтик, бүген 60 предприятиедә өч меңнән артык һава пычраткыч чыганак бар. 2007 елда алардан без сулый торган һавага 29 мең тоннага якын зарарлы матдә бүленеп чыккан.

Әлеге хәлне җиңеләйтү өчен "Татнефть" җәмгыяте тарафыннан хәзер күп чаралар күрелә. Компаниянең 2000-2015 елларга исәпләнгән экология программасы буенча нефть тапканда барлыкка килә торган калдыкларны юк итүгә нык игътибар бирелә. Калдыкларның зур өлеше икенчел чимал ясауга юнәлдерелә.

Нефть продукциясеннән нәрсәләр ясалганын күбебез чамалап әйтә алса да, аның ни рәвешле җир астыннан алынуын бары тик чын нефтьче генә белә торгандыр, мөгаен. Табигать биргән кара алтынны бораулап алу бер көч таләп итсә, шул вакытта экологиягә китерелгән зарарны булдырмый калу тагын да зуррак көч куюны сорый.

Җир өстенә чыгарылган нефть, "яшәү" шартлары үзгәрү сәбәпле, төрле зарарлы матдәләр бүлеп чыгара. Элегрәк нефтьчеләр эш барышында жиргә агып, балчык белән кушылган углеводород чималын ачык амбарларга жыя торган булганнар. Шулай нефть күлләре барлыкка килгән. Болар суны, һаваны һәм жирне агулап яткан. "Татнефть" бу афәттән котылу өчен калдыкларны юк итүче корылма төзергә мәжбүр булган. Хәзерге вакытта компаниянең шундый дүрт корылмасы эшли. Алар аерып биргән нефть сатуга озатыла, суы катлам басымын тотрыкландыруга китә, ә инде калган каты калдыклар сәнәгать мәйданнарын һәм юлларны төзекләндерүгә тотыла. Бүгенгә шушы рәвешле 1,4 миллион тонна нефть калдыгы эшкәртелгән. Нефтьне жылытудан барлыкка килә торган газ, нигездә, азот, углекислы газ һәм сероводород катнашмаларыннан гыйбарәт. Андагы метан күләме дә 41,5 процентка кадәр житәргә мөмкин. Компаниянең әлеге проблеманы хәл итү өчен 2009-2013 елларга исәпләнгән программасы бар. Аны тормышка ашырырга гына кирәк.

Үзгәрәсе килмиме, куәт җитмиме?

Табигатьне саклау нефтьчеләр белән генә чикләнми. Ышләндерү мәсьәләсе дә, жир, каты көнкүреш калдыклары мәсьәләсе дә бар. Комиссия вәкилләре регионда ярты еллап элек булып, бу юнәлешләрдә күп кенә кимчелекләрне теркәгән булганнар. Шуңа күрә утырышта чыгыш ясаган экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары Марат Мәһдиев сүзен башкарылган эшләрдән башлады.

– Бу якларда яшеллән-дерү эшләренә игътибар бирә башлаганнар. Законсыз барлыкка килгән чүплекләрне юк итүдә үзгәреш күренә, – диде министр урынбасары.

– Мисал өчен, элегрәк ачыкланган шундый 30 чүплекнең бүген барысы да диярлек юк ителгән. Республика буенча игълан ителгән икеайлык барышында авыл, бистә һәм бакча мәйданнарыннан 10 мең кубометрлап каты көнкүреш калдыгы жыеп алынган. 85 яңа чүп контейнеры сатып алынган, алар өчен яңа алты мәйдан төзелгән. – Марат Мәһдиев регионда яраксызланган авыл хуҗалыгы жирләрен элекке хәлгә кайтару буенча да шактый гына эш алып барылганлыгын ассызыклады. – Урман полосалары күбәйгән. Соңгы вакытта гына да 131 гектарда яшь үсентеләр утыртылган.

Әмма мондый урык-сурык эш белән генә табигатьне савыктырам димә. Бүген сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары белән идарә итү схемасы төзү көн кадагында тора. Ләкин ул Ык буе идарәсенә кергән бер генә район тарафыннан да төзелмәгән. Монда "башкарылмаган"нар исемлеге шактый озын булып чыкты. Жыентык суларны чистарту корылмаларының нәтиҗәлелеген арттыру буенча бармакка бармак сугылмаган. Артезиан коеларын коммуналь хуҗалык предприятиеләре балансына күчерү хәл ителмәгән. Авылларда урнашкан 272 су суырту корылмасының нибары 40ы гына (15 процеттан да азрагы) файдаланыла ала. Калганнарының әлеге эшкә лицензиясе рәсмиләштерелмәгән. Ярты ел эчендә Азнакай белән Баулыда барысы ике кое лицензияләнгән. Мөслим белән Ютазы әлеге эшләргә гомумән тотынып та карамаган.

Азнакайда төзелергә тиешле унбер үләт базының бүген нибары бишесе генә сафка басарга әзер. Калганнары корылып кына ята. Райондагы май заводында локаль чистарту жайланмаларын төзү эше дә туктатылган. Район жирендә урнашкан иске чүплек мәйданнарын тәртипкә салу шулай ук күз уңыннан ычкынган. Министрның беренче урынбасары икенчел чимал жыю пунктларына аеруча игътибар житмәвен шулай ук тәнкыйть утына тотты. Ярты ел эчендә биредә бер генә яңа пункт та ачылмаган. Пластик калдыкларны эшкәртүче чүп аралау линиясе хәзерге вакытта үзгәртеп кору өчен туктатылган.

Баулы районының да хәлләре Азнакайныкыннан шәбрәк күренми. Әзер булырга тиешле 6 үләт базының әле һаман берсе төзелмәгән. Министрлар Кабинеты тарафыннан 19 миллион сумга якын акча бүлеп бирелгән булса да, Баулы шәһәрендәге нәҗес суларны чистарту корылмаларын төзекләндерү ахырынача житкерелмәгән. Каты көнкүреш калдыкларын аралау хәл ителмәгән. Районда 120 чүп контейнеры житешми.

Ютазыда да табигатьне савыктыра алмаудан ыңгырашырга сәбәпләр житәрлек. Биредә үләт базларына кытлык. Төзелергә тиешле алты базның икесе генә әзер. Урыссудагы тәүлегенә 4200 кубометр егәрлек белән эшләүче чистарту корылмасында тынлык хөкем сөрә. Финанс чыганаклары табылмау сәбәпле Урыссудагы иске чүп урыннарын савыктыру тиз генә хәл ителмәскә охшаган.

Мөслимдә дә әзер булырга тиешле 5 үләт базының икесе генә төзелеп беткән. Нәҗес суларын чистартучы корылмаларны үзгәртеп кору, төзекләндерү эшләре төгәлләнмәгән. Ярты ел эчендә бер генә икенчел чимал жыю пункты да ачылмаган.

Чыгышта яңгыраган житешсезлекләр экология проблемаларының бер өлеше генә, ди белгечләр. Шуңа да Экология һәм табигый байлыклар министры Әгъләм Садретдинов муниципаль оешма житәкчеләрен әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә министрлык һәм үз жирләрендәге предприятиеләр белән тыгызрак эшләргә чакырды.

– Табигатькә һәр яклап басым ясауны киметмәсәк, тирә-як торышының сыйфатын яхшырту турында сүз алып бару бик читен, – диде министр.

Чулпан ГЫЙНИЯТУЛЛИНА.
Гөлназ САТИЕВА фотолары

Инеш бәете

Чистай районы, Яуширмә авылы, Кече Бахта, Иске Иванаево авыллары Олы Бахта, Алексеевск районының Кыр Шонталысы Шонтала инеше буена урнашкан. Хәзерге көндә кырык-илле ел элек булган елгалардан аларның исемнәре генә утырып калды, диярлек. Аларның яр буена ташланган тирес, чүп-чар, шешә, чүпрәк-чапрак, тимер-томыр калдыклары, хайван-кош үләксәләре сасысын чыгарып, суны гына түгел, һаваны да сөрсетеп ята. Су кондызлары да инешләребезне саектыру өчен бик тырыша. Алар үрчегән. Таллар, өянкеләрне үткен тешләре белән аударып, суның агышын туктата. Мондый тонган суларда балык та үрчеми, кысла да яшәми. Мин, өлкән кеше буларак, шунысына гаҗәпләнәм, ни сәбәпле авыл жирлекләре, мәктәпләр табигатьне элеккеге хәленә китереп савыктыру өчен бармакка бармак сукмыйлар икән? Хөрмәтле редакция! Шушы авыр уйлар тәэсирендә язылган шигыремне сезгә дә юллыйм.

* * *

Еллар буе, тыныч кына,
Үз көенә ага инеш.
Язлар гына бер дулатып
ала үзен,
Күрсәтеп тын инешнең
гайрәт көчен.

Элек заман хәтфә кебек
яшел ике ягы,
Ятып су эчәрлек булган
инеш.
Булган аның төнбоеклы
тобалары,
Шул тобада атлар
йөздергәннәр, имеш.

Суда йөзгән инеш тулы
чуртан, чабак,
Яшәгән ди бихисап күп
алабуга, кызылканат.
Тоткан балык бала-чага,
һәвәскәрләр, кармак салып.
Бик уңганнар –
тал-чыбыктан морда үреп.

Су кергәннәр ир-егетләр
челлә житкәч,
Кер юганнар басмаларда
хатын-кызлар.
Ә кичләрен, су буенда,
учак ягып,
Гармун тартып, жыр
сузганнар гашыйк парлар.

Вәт замана, кадерсез дә
калды инеш,
Бар шакшыны шунда илтеп
ташла, имеш.
Үзең шуны белеп-торып,
файда көтеп,
Күзле булып, сукыр килеш
яшә, имеш.

Оятыннан, күренмим
хет күзгә диеп,
Бер заман сусыз калыр әле
инеш,
Без, адәмнәр, әле тагын
күп яшәрбез,
Шапшаклана, зур гөнаһка
баткан килеш.

Шәүкәт КАМАЛОВ.
Алексеевск районы,
Кыр Шонталысы авылы

Авыл сабый бала кебек

Җәй башы – табигатьнең иң гүзәл чагы. Агачларга әле тузан кунарга өлгермәгән. Бакча-урамнар шау-чәчәктә. Шәһәр һәм калалар чистарынып, әйләнә-тирәне тәртипкә китергәннәр. Бөтен жирдә дә ул шулаймы соң? Әйдәгез, үзебез яши торган авыл яки бистәгә югарыдан күз атыйк.

Бер йорт алдында салам чүмәләсе өелеп торганын күреп алдык. Икенчесе каршында утын калдыклары, төзелеш материаллары аунап ята. Менә шулай һәр хуҗа ихатадан артканын урамга чыгаруны мәхкуль күрәбез без дә. Терлек-туары булган хуҗалыклар аерата пырдымсыз кылана. Кайберәүләр хәтта тиресен дә урамга чыгарып өюдән тайчанмый. Транспорт тапса, инеш буйлары, урман кырыйларына илтеп аудара.

Безнең бабайлар инеш янына утырырга тырышкан. Шул сулыкларның бүгенге хәле коточкыч бит. Елга, күлләр тирәсендә нинди генә чүп-чар юк. Авылның бар шакшысы шунда. Сулыкларның күбесе тончыгып ята, кибә, корый.

Республикада ике айлык чистарыну тәмамланды, дип язалар. Шулай да ихата тирәсендә, елга буйларына күз салыгыз әле. Аларны тәртипкә китерү өчен нәрсә булса да эшләргә өлгердегезме? Әлләә авыл, бистә, үз нәжесенә баткан сабый бала кебек, читтән килгән берәүнең чистартуын көтәме?

Хәлим ӘЛИМОВ